КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 август г.Казань № 638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 19 март, 168 нче карары белән расланган Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 19 март, 168 нче карары белән расланган Шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын аларны Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә арттырган өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Түләү күләме Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре, дәүләт милке чикләнмәгән җирләр яки җир кишәрлекләре белән яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлегенең мәйданы арткannan соң шәхси милеккә бирелергә тиеш җир кишәрлегенең кадастр бәясе белән яыңадан бүлү турында гариза бирелгән көндә шәхси милектә булган җир кишәрлегенең кадастр бәясе арасындагы аерма буларак билгеләнә, моңа бу Тәртипнең 4 пунктында күздә тотылган очрак керми.».

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин